**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «18» октябреннән № 300

«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге 590 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында, 2022 елда күрсәтелгән субсидияләрне һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 31 августындагы 354 номерлы, 2021

елның 08 декабрендәге 492 номерлы, 2022 елның 14 апрелендәге 120 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибендә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешен үтәүне тикшереп торалар. Муниципаль финанс тикшерү органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыралар.».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына 2 нче кушымтада Исхакова Луиза Камил кызының вазыйфасын яңа редакциядә бәян итәргә – «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча)», Иванова Нина Николаевнаның вазыйфасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге башлыгы», Прыткова Валентина Александровнаның вазыйфасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Чистай шәһәре дәүләт статистикасы бүлегенең әйдәүче белгеч – эксперты (Яңа Чишмә авылы)».

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч

һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына 2 нче кушымтадагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси хуҗалыкларга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау комиссиясе составына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы рәисе Завалишина Наталья Александровна кертергә (килешү буенча).

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына 2 нче кушымтадагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси хуҗалыкларга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау комиссиясе составыннан Тухтаманова Елена Ивановнаны төшереп калдырырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов